

8 сентябрьдә Россиядә Финансист коне билгеләп vтелде. Кvп нәрсә аларнын һонәри осталыгына, тогәллегенә һәм ныклыгына бәйле. Белемлелек һәм игътибарлылык, жаваплылык һәм фаразлый белv, интеллект һәм коммуникабельлек – профессиональ финансистнын шәхси сыйфатларынын тулы булмаган исемлеге. Кадошкино муниципаль районы хаки-миятендә алты финансист эшли: Наталья Викторовна Камышова, Светлана Әминовна Байчурина, Любовь Владимировна Лапшина, Альбина Әнвәр кызы Поташова, Наталья Юрьевна Захаркина. Ә бvлек белән Надия Руслан кызы Уторова житәкчелек итә. Алар барысы да, һичшиксез, бик белемле һәм жаваплы, vз эшләренен осталары.

Светлана Әмин кызы Байчурина Кадошкино муниципаль районы администрациясенен финанс бvле-гендә 2005 елдан алып эшли. Анын турында барлык коллегалар да бик ях-шы фикердә. Ул һәрбер эшкә жаваплы могаләмәдә, аралашучан, беркайчан да ярдәмнән баш тартмаячак, диләр анын турында. Тик анын бер минусы бар – vзен мактый алмый. Моннан тыш, Светлана Әминовна vз эшен яхшы белә, ул әле менә дигән хужабикә дә. Анын vз йорты, бакчасы, ишегалдында чебиләр, vрдәкләр, сарыклар бар. Латышовка авылында яши бит ул, әмма районда эшли. Бу юлны (7 км) vтәр очен дә вакыт табарга кирәк бит. Әмма 15 ел эчендә ул ияләште инде.

Светлана тумышы белән Латыш авылыннан, әмма ана биш яшь булганда, әти-әнисе Кадошкино бистәсенә кvчеп яши башлый. Ә язмыш vз юлын сала: 2001 елда кияvгә чыккач, туган авылына әйләнеп кайта ул. Ире Илшат белән алар Фаиль белән Эльвинаны тәрбиялиләр. Сvз унаенда, улы быел Н.П. Огарев исемендәге МДУнын электроника һәм светотехника факультетынын беренче курсына укырга керде, ә кызы алтынчы сыйныфка китте.

Светлана Әминовна Кадошкино урта мәктәбенен 10нчы сыйныфын тәмамлаганнан сон, Н.П. Огарев исе-мендәге МГУнын икътисад факультетына укырга керә. Дорес, читтән торып укыган. Администрациягә әйдәп баручы белгеч булып эшләргә килә, аннары аны баш итеп билгелиләр, хәзер финанс идарәсе консультанты вазыйфасын vти. Әнгәмәдәшебез vзе әйткәнчә, беренче вакыт бик авыр булды, әмма хезмәттәшләре кыенлыкларны жинәргә булыштылар. Коллектив бик тату.

- Мина һонәрем ошый, - дип билгеләп vтә Светлана Әминовна. - Саннар белән эшләргә, санарга, жыярга яратам... ә менә инша яза алмыйм. Гәрчә укырга бик яратсам да. Дорес, укырга бик ук вакыт калмый. Финансист эше бик катлаулы бит. Законнар vзгәрә, һәм һәрвакыт хәбәрдар булу очен, бу vзгәрешләрне кvзәтеп торырга кирәк. Финанс олкәсе хезмәткәре очен белем беренче урында. Ә безнен коллективта бар да яхшы! Тату

коллективта эшләү үзе бәхет бит.

**Наилә НАСЫРОВА**